КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 29 декабрь г.Казань № 1101

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» 2011 ел, 20 май, ТРЗ-26 нчы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру чаралары хакында» 2012 ел, 24 сентябрь, 798 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» 2011 ел, 20 май, ТРЗ-26 нчы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру чаралары хакында» 2012 ел, 24 сентябрь, 798 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 6 февраль, 66 нчы, 2015 ел, 12 сентябрь, 670 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау республика комиссиясе турында нигезләмәнең 1.1 пунктында «җинаятьләр һәм җәмгыятькә каршы гамәлләр» сүзләрен «җинаятьләр, башка хокукка каршы һәм (яки) җәмгыятькә каршы гамәлләр, шулай ук аларны суицидаль гамәлләргә өндәү очраклары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау муниципаль комиссияләре турында нигезләмәнең 1.1 пунктында «җинаятьләр һәм җәмгыятькә каршы гамәлләр» сүзләрен «җинаятьләр, башка хокукка каршы һәм (яки) җәмгыятькә каршы гамәлләр, шулай ук аларны суицидаль гамәлләргә өндәү очраклары» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин